# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Әтнә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Әтнә муниципаль районы составына керүче "Кышлау авыл җирлеге" һәм "Өҗем авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**


"Әтнә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әтнә муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Әтнә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *2(11) - 11(12)* | - Марий Эл Республикасы |
| *11(12) - 28(47)* | - Арча муниципаль районы |
| *28(47) - 2(11)* | - Биектау муниципаль районы |

"Әтнә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге
составына керүче авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Олы Әтнә авыл җирлеге |
| 2 | Олы Мәңгәр авыл җирлеге |
| 3 | Югары Сәрдә авыл җирлеге |
| 4 | Комыргуҗа авыл җирлеге |
| 5 | Күәм авыл җирлеге |
| 6 | Күлле Киме авыл җирлеге |
| 7 | Күңгәр авыл җирлеге |
| 8 | Кышлау авыл җирлеге |
| 9 | Түбән Бәрәскә авыл җирлеге |
| 10 | Түбән Көек авыл җирлеге |
| 11 | Яңа Шашы авыл җирлеге |
| 12 | Өҗем авыл җирлеге"; |

2) 10 нчы кушымтада:

а) бишенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

"Кышлау авыл җирлеге чиге Яңа Шашы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кышлау, Яңа Шашы авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кызыл Утар авылыннан 4,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км инеш агымы буенча аска таба башка инеш белән кушыла торган җиргә кадәр уза, аннары көнбатышка таба борыла һәм 1,1 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 180 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 480 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, автомобиль юлын кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, 700 м инеш агымы буенча өскә таба, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 490 м төньякка таба, 280 м көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң шул ук юнәлештә урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,38 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң шул ук юнәлештә 660 м чокыр төбе буйлап инешкә кадәр бара, аннары, Күшәр – Ключи-Сап автомобиль юлын кисеп үтеп, әлеге инеш агымы буенча 4,5 км аска таба аның Шашы елгасына коя торган урынына кадәр, шуннан соң 2,5 км Шашы елгасы агымы буенча аска таба 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кышлау авыл җирлеге чиге Өҗем авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнчыгышка таба Иске Өҗем – Югары Шашы автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң 650 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Кышлау – Яңа Өҗем автомобиль юлын кисеп үтеп, 8,15 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, аннары төньяк-көнчыгышка таба 910 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 35 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,18 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньяк-көнбатышка таба һәм 50 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, аннары шул ук юнәлештә 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Кышлау – Яңа Өҗем автомобиль юлын кисеп үтеп, 500 м шуннан соңгы урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара. Аннары чик, озын чокырны әйләнеп үтеп, сынык сызык ясап, 4,2 км бара, Кышлау – Яңа Өҗем автомобиль юлына кадәр уза, шушы юл буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка борыла һәм урман полосасының көньяк чиге буйлап 500 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, озын чокырны әйләнеп үтеп, 2,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ура елгасына кадәр бара, Яңа Өҗем – Иске Өҗем автомобиль юлын кисеп үтеп, Кышлау, Өҗем авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ура елгасы үзәнендә Иске Өҗем авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) җиденче – унынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

"Кышлау авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып Әтнә муниципаль районы чиге буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

3) 13 нче кушымтада:

а) икенче абзацта ", Өҗем" сүзен төшереп калдырырга;

б) җиденче абзацта "Яңа Шашы авыл җирлеге, Кышлау авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге" сүзләрен "Кышлау, Яңа Шашы авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

в) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңа Шашы авыл җирлеге чиге Кышлау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км инеш агымы буенча аска таба башка инеш белән кушылган җиргә кадәр уза, аннары көнбатышка таба борыла һәм бу

инеш агымы буенча 1,1 км өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 180 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 480 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, автомобиль юлын кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, 700 м инеш агымы буенча өскә таба, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 490 м төньякка таба, 280 м көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң шул ук юнәлештә урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,38 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң шул ук юнәлештә 660 м чокыр төбе буйлап инешкә кадәр бара, аннары, Күшәр – Ключи-Сап автомобиль юлын кисеп үтеп, әлеге инеш агымы буенча 4,5 км аска таба аның Шашы елгасына коя торган урынына кадәр, шуннан соң 2,5 км Шашы елгасы агымы буенча аска таба 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

г) тугызынчы һәм унынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

4) 14 нче кушымтада:

а) икенче абзацта ", Яңа Шашы" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Өҗем авыл җирлеге чиге Кышлау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнчыгышка таба Иске Өҗем – Югары Шашы автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң 650 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Кышлау – Яңа Өҗем автомобиль юлын кисеп үтеп, 8,15 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, аннары төньяк-көнчыгышка таба 910 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 35 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,18 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 төньяк-көнчыгышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м төньяк-көнбатышка таба һәм 50 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, аннары шул ук юнәлештә 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Кышлау – Яңа Өҗем автомобиль юлын кисеп үтеп, 500 м шуннан соңгы урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара. Аннары чик, сынык сызык ясап, 4,2 км бара, озын чокырны әйләнеп үтеп, Кышлау – Яңа Өҗем автомобиль юлына кадәр уза, шушы юл буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка борыла һәм урман полосасының көньяк чиге буйлап 500 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм, озын чокырны әйләнеп үтеп, 2,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ура елгасына кадәр бара, Яңа Өҗем – Иске Өҗем автомобиль юлын кисеп үтеп, Кышлау, Өҗем авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ура елгасы үзәнендә Иске Өҗем авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) алтынчы һәм җиденче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

**3 статья**


Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 31-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Әтнә муниципаль районының «Кышлау авыл җирлеге» һәм «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чиктәш чиге участогы карта-схемасы




Шартлы билгеләр

район чиге

җирлекләрнең чикләре

Кышлау авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Өҗем авыл җирлеге территориясе

торак пункт